ПӘНҖЕШӘМБЕ
29 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 49 (5849)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат кузәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—73, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯНЕ МАРКСИЗМ-ЛЕНИНИЗМ БЕЛӘН КОРАЛЛАНДЫРУ ЭШЕН КӨЧӘЙТИК

Тарих күрсәткәнчә, дөньяда бер генә дәүләт тә үз интеллигенциясеннән башка эш итә алмаган һәм итә алмый. Безнең дәүләтебез—эшчеләрнең һәм крестьяннарнең социалистик дәүләте үз интеллигенциясеннән башка эш итә алмавы бигрәк тә табигый нәрсә.

Ләкин ике дәүләт арасында—эшче һәм крестьяннарнең социалистик дәүләте белән капиталистик дәүләт арасында принципиаль аерма булган кебек, ике интеллигенция арасында да шундый ук принципиаль аерма бар. Капитализм шартларында интеллигенция үзенең социаль чыгышы ягыннан иң зур күпчелеге белән эксплоататорлардан—дворяннардан, промышленниклардан, сәүдәгәрләрдән, кулаклардан һәм башка шундыйлардан тора. Димәк, аның турыдан-туры эксплоататор сыйныфлар белән бәйләнгән, аларның интересларын теше-тырнагы белән яклаучы, аларга якыннан торып хезмәт итүче булуы көн кебек ачык.

Безнең илдә—социализм илендә бу эшнең торышы бөтенләй башкача. Совет интеллигенциясе үзенең социаль чыгышы ягыннан да һәм көндәлек эше ягыннан да эшчеләр сыйнфы һәм крестьяннар белән турыдан-туры бәйләнгән, социалистик дәүләт өчен, Ватан өчен җаны-тәне белән бирелеп эшли. Безнең социалистик интеллигенциябез — ул бөтенләй яңа тип интеллигенция, аның кебек интеллигенциянең дөньяда бер генә илдә дә булганы юк.

Безнең партияле һәм партиясез кадрларыбыз совет интеллигенциясенең зур өлешен тәшкил итә. Алар хуҗалыкның һәм культураның барлык тармакларында эшлиләр. Социализм иле алдында торган бөек һәм мактаулы бурычларны уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен көрәшәләр.

Совет интеллигенциясе өстенә йөкләнгән катлаулы һәм мактаулы бурычларны уңышлы рәвештә үтәү өчен безнең интеллигенциябез дөньяда иң алдынгы һәм иң революцион теория — марксизм-ленинизм теориясе белән коралланган булырга тиеш.

Ул, җәмгыятнең үсеш законнарын, эшчеләр хәрәкәтенең, пролетар революциянең, социалистик тормышыбызның үсеш законнарын ныклап белергә һәм аларны социалистик төзелешкә җитәкчелек итү буенча практик эштә файдалана белергә тиеш.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ басылып чыгу интеллигенциябезне революцион теория белән коралландыруда гаять зур чараларның берсе булды. Хәзерге көндә йөз меңнәрчә кадрларыбыз, интеллигенциябез марксизм-ленинизм теориясен намус белән үзләштерәләр. Безнең республикабызда да мондый фактлар гаять күп.

Менә шул күп фактларның берничәсе. Казан Дәүләт университетының физика-математика профессоры иптәш Ерсицкий марксизм-ленинизм теориясен намус белән өйрәнүчеләрнең берсе. Ул болай ди: „Марксизм-ленинизм теориясен өйрәнү көндәлек фәнни эшемдә миңа зур ярдәм итә, математика фәне өлкәсендәге хезмәтләремне марксизм-ленинизм фәне күрсәтмәләре нигезендә алып барам“. Шул ук университетның карт профессорларыннан, физика-математика галиме иптәш Парфентьев: „Ленинның материализм һәм эмпириокритицизм“ дигән гүзәл әсәрен мин берничә тапкыр укып чыктым. Бу әсәр табигат һәм физика-математика фәне өлкәсендә эшләүче галимнәргә дөрес юнәлеш бирә, көндәлек эштә зур ярдәм итә“ ди. Персицкий, Парфентьев, Сементовский кебек марксизм-ленинизм фәнен тирәнтен өйрәнүчеләрне, аны үзләренең көндәлек фәнни хезмәтләрендә файдаланучыларны күпләп санарга була. Врачларның квалификацияләрен күтәрү институты профессоры Козлов, Казан Химико-технология институты фәнни работниклары Залесский, Андреев, Мойсак, Праксин, Мочалов, Дезидирьев һәм башка бик күп фәнни работниклар бу өлкәдә башкаларга үрнәк булып торалар.

Совет укытучысы булу социализм илендә иң мактаулы эшләрнең берсе. Укытучыга киләчәк буынны тәрбияләү кебек гаять җаваплы эш йөкләтелгән. Бу бурычны хәзерге көннең сорауларына җавап бирерлек итеп үтәү өчен укытучы марксизм-ленинизм теориясе белән коралланган булырга тиеш. Күп санлы укытучылар армиясе эчендә хәзер „кыскача курс“ның барлык бүлекләрен дә өйрәнгән һәм хәзер марксизм-ленинизм классикларының аерым әсәрләрен тирәнтен өйрәнүгә керешкән иптәшләр бик күп.

Шулай ук күп кенә инженер-техник работниклар, медицина работниклары, агрономнар һәм башкалар марксизм-ленинизм теориясен үзлекләреннән тирәнтен үзләштерәләр.

Ләкин үзләренең политик һәм теоретик артталыкларын бетерү өстендә эшләү өчен „вакыт тапмаучылар“, бу эштә сүлпәнлек күрсәтүчеләр интеллигенция арасында да, шулай ук җитәкче кадрларыбыз арасында да бар әле. „Кыскача курс“ның басылып чыгуына ел ярым вакыт үтүгә карамастан, беренче-икенче бүлекләрне өйрәнү белән генә канәгатьләнгән укытучылар, фәнни работниклар, инженер-техниклар, җитәкче работниклар байтак әле.

„... Үзен ленинче дип атап та үзенең специальностена кереп бикләнгән, әйтик, математикага, ботаникага яки химиягә кереп бикләнгән һәм үзенең специальностеннан ары бер нәрсәне дә күрмәүче кешене чын ленинче дип санап булмый. Ленинче булган кеше фәннең үзе яраткан тармагының гына белгече булып кала алмый,—ул бер үк вакытта үз иленең язмышы белән якыннан кызыксынучы, иҗтимагый үсеш законнары белән таныш, бу законнардан файдалана белүче һәм илгә политик җитәкчелеккә актив катнашырга омтылучы политик булырга—җәмагат эшчесе булырга тиеш“. **(Сталин).** Юлбашчының бу күрсәтмәсен бер генә минутка да онытырга ярамый, аны тормышка ашырырга тиешбез.

Социалистик интеллигенциябезнең, җитәкче кадрларыбызның теоретик белемнәрен партиябезнең Үзәк Комитеты һәм иптәш Сталин таләп иткәнчә оештыру өчен бездә бөтен мөмкинлекләр дә бар. Партия оешмалары бу өлкәдә үзләренең эшләрен тагын да яхшыртырга, интеллигенция һәм кадрларыбызга марксизм-ленинизм теориясе белән коралланууда конкрет ярдәмне көчәйтергә тиешләр. Партиянең район конференцияләре бу мәсьәләгә аеруча игтибар бирергә тиешләр.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

27 нче февральдә Карелия бугазында безнең частьләр дошманның ныгытмаларына һөҗүм итеп, ныгытылган 13 оборона пунктын алдылар. Шуларның 9 ы тимербетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация күп кенә районнарда дошман гаскәрләрен һәм аның сугыш объектларын уңышлы төстә бомбага тотты. Һава сугышларында дошманның 6 самолеты бәреп төшерелде.

ВКП(б) ның КАЗАН ШӘҺӘР ОЕШМАСЫНЫҢ V нче КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ДЕЛЕГАТЛАРЫ ИГТИБАРЫНА

Партиянең шәһәр күләмендәге V нче конференциясе шушы елның 3 нче мартында, 18 сәгаттә Менжинский исемендәге клуб бинасында ачыла.

Делегатлык билетлары һәр көнне иртән 9 сәгаттән 15 сәгаткә кадәр һәм 17 сәгаттән 21 сәгаткә кадәр ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты бинасында 19 нчы бүлмәдә бирелә. (Астрономический урам, 15/19).

Оештыру комиссиясе.

Язу машиналары заводының инструментальный цехы слесаре стахановчы иптәш Б. Камалиева. Ул үзенең нормасын һәр вакытта 160—170 процент үтәп килә.

И. Галиев фотосы.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

ОРЛЫК БЕЛӘН КОЛХОЗАРА ЯРДӘМЛӘШҮ

ӘГЕРҖЕ, 27 февраль. **(Махсус хәбәрчебездән телефон буенча).** Районның Буденный һәм Маркс исемендәге колхоз членнары чәчү орлыгы белән колхозара ярдәмләшү мәсьәләсен шушы көннәрдә үзләренең гомуми җыелышларында тикшерделәр.

Буденный исемендәге колхоз үзеннән арткан орлыктан „Кызыл таужамал“ һәм Чапаев исемендәге колхозларга 26 шар центнер солы бирә.

Маркс исемендәге колхоз үзеннән арткан орлыктан „Октябрьнең XI еллыгы“ һәм „Беренче Май“ колхозларына 50 шәр центнер, Сталин исемендәге колхозга 48 центнер, Каганович исемендәге колхозга 30 центнер чәчү орлыгы бирергә булды.

М. Хәмидуллин.

***

Тымытык районының „Мелиорация“ колхозы членнары җәмагатьләштерелгән терлекләрнең көчле азык белән тәэмин ителүен яхшырту өчен колхозга бурычка 500 пот ашлык бирделәр. Районның башка колхозларында да шулай эшләргә мөмкин. Тик бу турыда колхозчылар арасында аңлату эшләрен генә оештырасы бар. Ә Тымытыкта бу эш белән яхшылап шөгылләнмиләр әле.

И. Соловьев.

КОЛХОЗ ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕР

Кызыл Йолдыз районының Камиль Якуб исемендәге колхозы членнары язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнү өчен көрәшәләр. Колхозда язгы чәчү өчен орлыклар җитәрлек хәзерләнгән. Машиналар һәм инвентарьлар яхшы сыйфатлы итеп ремонтланган. Кар тоту һәм басуга тирес чыгару планнары тулысынча үтәлгән. Ашламалар җыю эше дә уңышлы бара. 120 баш ат өчен 400 центнер фураж һәм 600 центнер печән хәзерләнеп куелган.

Бу колхоз быел Сталинчыл югары уңыш алуга ирешү өчен Фрунзе исемендәге колхозны социалистик ярышка чакырды.

Әхметов.

КАДРЛАР ХӘЗЕРЛӘҮГӘ ИГТИБАРСЫЗ КАРАШ

Чистай МТС җитәкчеләре кадрлар хәзерләүгә игтибар бирмиләр. Комбайнчылар хәзерләү буенча Усадыда ачылган курска декабрь аенда ук җибәрелергә тиешле 11 кеше әле дә җибәрелмәгән. МТС директорлары Зарипов һәм Габидуллин иптәшләр „Урып-җыюга кадәр вакыт күп әле, ничек тә өлгерербез“ дип зарарлы тынычлануга бирелгәннәр.

Тракторчылар хәзерләү буенча МТС янында оештырылган курсларда укучыларга тиешле шартлар булдырылмаган: күргәзмә пособиеләр, язу-сызу әйберләре җитәрлек түгел. Укучылар өчен газета һәм журналлар яздырылмаган. Стена газеталары да чыгарылмый. Укучылар арасында социалистик ярыш формаль рәвештә генә оештырылган. Укулар башлануга 3 айдан артык вакыт үтсә дә, ярыш договорларының үтәлеше бер тапкыр да тикшерелмәгән.

Механизатор кадрлар хәзерләү эшенә „Ударник“, „Красный луговик“, „Смена“, „Борьба за урожай“, „Урал“ һәм „КИМ“ колхозлары җитәкчеләре дә бик салкын карыйлар. Алар укучыларга договор буенча бирелергә тиешле азыкларны вактында җибәрмиләр.

Район җир бүлеге, район советының башкарма комитеты һәм райком җитәкчеләре дә механизатор кадрлар хәзерләү эшеннән читләшкәннәр. Алар бу эшнең барышы белән тиешенчә кызыксынмыйлар

К. Исламов.

КОЛХОЗЛАРДА ОТЧЕТ ҖЫЕЛЫШЛАРЫ

Юдино районының „Горняк“ колхозы правлениесе үзенең 1939 нчы елгы эше турында колхозчылар җыелышында отчет бирде.

„Горняк“ колхозы өч ел буена һәр гектардан кимендә 76 пот, ә узган ел 80 пот уңыш алды. Орлыклык участкыдагы уңыш 100 поттан да артык булды. Колхозчыларның бер хезмәт көненә өч килограмм бөртекле ашлык, өч килограммнан артык бәрәңге туры килә.

Җыелыш, правлениенең отчет доклады буенча фикер алышулардан соң, быел гектардан 100—110 пот иген уңышы алу өчен көрәшергә дигән карар чыгарды. Колхоз язгы чәчүгә хәзерлекне яхшы алып бара: орлыклар тазартылды, авыл хуҗалыгы коралларына, сбруйларга ремонт ясалды. Колхозда даими звенолар оештырылды. Алар үзара ярыш договоры төзеделәр. Хәзер җирле ашламалар җыялар, кар тоту чараларын үткәрәләр.

Отчет җыелышы Фрунзе исемендәге колхозда да шундый ук активлык белән үтте. Бу колхоз үткән ел һәрбер гектардан уртача 96 пот иген уңышы алган. Терлекчелекне үстерүдә дә зур уңышларга ирешкән. Колхозда өч ферма бар. Терлекчелектән килгән тулай доход 25 мең сумга җитә. Колхозчылар бер хезмәт көненә 3,5 килограмм бөртекле ашлык һәм 2 сум 50 тиен акча алалар.

Җыелыш быел гектардан кимендә 16—17 центнер уңыш алуга ирешү турында карар кабул итте.

(ТатТАСС).

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БРЮССЕЛЬ, 27 февраль. „Журналь“ газетасының 25 нче февральдәге хәрби күзәтүендә болай диелә: „Фронтның Рейн буендагы участкысында ике як ярда урнашкан дошман частьләре арасында атыш булды. Диңгездә әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Күренү начар булу авиациянең активлыгын киметте, ләкин Германиянең берничә самолеты көнчыгыш һәм төньяк Франция өстендә очты. Англичаннар тирән разведка алып бардылар. Англия самолеты Белгиядә җиргә төшәргә мәҗбүр булды. Самолетның экипажы интернировать ителде“.

ПАРИЖ, 27 февраль. Парижда кичә кич һәм бүген иртә белән иглан ителгән рәсми белдерүләрдә „бөтен фронтта тынычлык“ турында хәбәр ителә.

ЛОНДОН, 27 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең 5.936 тонна авырлыгындагы „Клан Моррисон“ пароходы Төньяк диңгездә минага бәрелеп баткан. Команданың бер члены һәлак булган, 15 члены яраланган.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Германиянең 4.709 тонна авырлыгындагы „Вахехэ“ пароходының Англиянең сугыш карабы тарафыннан тотылып Англия портына алып кителгәнлеге турында рәсми рәвештә иглан ителгән. Германия командасы үз пароходын батырырга өлгермәгәндер дип уйлыйлар.

ЛОНДОН, 27 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Төньяк диңгезнең төньяк өлешендә Швециянең 3.840 тонна авырлыгындагы „Сантос“ пароходы батырылган. Пароходта пассажирлар белән берлектә 30 лап кеше булган. Хәбәр итүләренә караганда, әлегә бары 12 кеше генә коткарылган.

ЛОНДОН, 27 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Германиянең „Оризаба“ пароходы Англия блокадасы аркылы үтәргә маташканда төньяк Норвегия ярлары якынында батырылган.

ЛОНДОН, 27 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең 4.580 тонна авырлыгындагы „Британиш индевор“ пароходын Германиянең су асты көймәсе торпедалап батырган. Командадан 5 кеше һәлак булган.

(ТАСС).

АНГЛИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ СССР ПОЛИТИКАСЫН ЯКЛЫЙЛАР

ЛОНДОН, 26 февраль. (ТАСС). 24 нче февральдә Нью-Каследә „Раше тудэй“ („Бүгенге Россия“) җәмгыяте членнарының конференциясе булды. Конференциядә эшчеләрнең 49 оешмасыннан сайланган 250 ләп делегат катнашты. Конференциядә тау эшчеләренең Көньяк Уэльс федерациясе председателе Хорнер речь сөйләде. Хорнер Советлар Союзының Финляндиядәге хәрәкәтләре турында сөйләде һәм аның речен конференциядә катнашучылар барсы да яхшы дип таптылар. Конференциядә Советлар Союзы политикасын яхшы дип табып һәм ак финнәргә ярдәм оештырырга маташучы сугыш уты кабызучыларга отпор бирергә җәмгыятнең барлык членнарын чакырып резолюция кабул ителде.

Лейбористлар оешмасының Сихэмдәге (Дергем графлыгы) район конференциясендә дә 24 нче февральдә Англия буржуазиясенең һәм лейборист лидерларның Советка каршы кампаниясен гаепләп резолюция кабул ителде. Конференциядә бу резолюциягә Советка каршы характерда „төзәтү“ кертергә маташу булды. Ләкин конференция аңа ныклы отпор бирде. Лейбористлар органының—Европадагы империалистик сугышны яклаучы һәм Англиядә Советка каршы кампанияне көчәйтүче „Дейли геральд“ газетасының позициясен делегатлар нык тәнкыйть иттеләр. Конференция делегатларының берсе „Дейли геральд“ның хәзерге редакторының хәтта лейбористлар партиясендә член да түгеллеген әйтте.

Англиянең зур промышленность үзәкләреннән берсендә—Манчестерда 25 нче февральдә 4 митинг булды. Бу митингларда Англия хезмәт ияләрен ак финнәргә ярдәм итүгә каршы көрәшкә чакырып резолюцияләр кабул ителде. Моның өчен массовый демонстрацияләр һәм предприятиеләрдә митинглар оештырырга карар бирелде.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясендә, Наньниннан көньяк-көнбатышта Фунань районында кытай гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителгән японнар колоннасының калдыгы Наньнин белән Циньчжоу арасында урнашкан Датанга чигенә. Кытай частьләре чигенүче япон частьләрен эзәрлеклиләр. Көнчыгыштан һөҗүм иткән кытайлар отряды Датан белән Циньчжоу арасында Наньнин—Циньчжоу шоссесен кискәннәр. 24 нче февральдә японнарның 3 меңкешелек отряды 10 орудие, берничә танк һәм 9 бомбардировщик ярдәме белән Наньнин—Биньян шоссесендә Утан якынында кытай позицияләренә атака ясады. Кытай частьләре уңышлы маневр белән японнарга ныклы удар ясадылар. Японнарның 1.500 ләп кешесе үтерелгән һәм яраланган, 3 танклары һәм 2 орудиеләре сафтан чыгарылган.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Японнар тылында, Аньхуэй провинциясе белән Цзянсу провинцияләре чигендә кытай частьләре Лансины алганнар. Сугышларда японнарның меңнән артык солдатлары һәм офицерлары үтерелгән һәм яраланган. Бу сугышлар турындагы тулы хәбәрләрдә 21 нче февральдә Лансидәге японнарны кытай частьләренең чолгап алганлыгы әйтелә. Япон гаскәрләренең чигенү юлларын кисеп, кытайлар 22 нче февральдә иртә белән Лансины штурмлый башлаганнар һәм аны төштән соң алганнар.

Хубэй провинциясендә кытай гаскәрләре Суйчжоу белән Аньлу арасындагы юлны (Ханькоудан төньяк-көнбатышта) берничә урыннан өзеп, 23 нче февральдә төнлә Аньлуга һөҗүм башлаганнар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Хэнань провинциясенең төньяк өлешендә 21 нче февральдә Даокоу—Цинхуа тимер юл тармагының көнбатыш чигендә Цзяоцзе өчен каты сугышлар башланган. Японнарның ныклы каршылык күрсәтүләренә карамастан, кытай частьләре штурм ясаганнан соң шул ук көнне шәһәргә бәреп кергәннәр һәм анда япон гарнизонына каршы урам сугышы башланган. 22 нче февральдә сугышлар дәвам иткән.

Шаньси провинциясендә соңгы атнада кытайлар берничә пунктны кире алганнар.

АНГЛИЯ ПРОФБЮРОКРАТЛАРЫНЫҢ РЕАКЦИОН ЧАРАЛАРЫ

ЛОНДОН, 28 февраль. (ТАСС). „Дейли уоркер“ ның хәбәр итүенә караганда, машина төзүчеләрнең берләштерелгән союзының күренекле 3 эшлеклесе бер такдим хәзерлиләр. Бу такдим буенча союзның башкарма комитеты сугыш вактында үз өстенә „гадәттән тыш полномочиеләр“ алырга тиеш булачак. Хөкүмәт моңа бик яхшы караячак, чөнки ул эшчеләрнең хезмәт хакын күтәрү өчен булган хәрәкәтләреннән курка. Газетаның язуына караганда, башкарма комитетка диктаторлык хокуклары бирү өчен маглүм адымнар ясалган инде. Бу хәл союз членнарының демократик хокукларын куркыныч астына куя. Әгәр башкарма комитет бу маневрны тормышка ашыра алса, ул илдә гадәттән тыш хәл сылтавы белән союзның ел саен була торган конференциясен бетерә алачак. Бу конференция майда җыелырга тиеш иде. Монардан тыш башкарма комитет союзның коммунист членнары өчен тагын да чикләүләр кертергә уйлый. Шик юк ки, бу чараларның барсын да милли конференция кире каккан булыр иде.

ПАРТИЯНЕҢ РАЙОН КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕНДӘ

БАУМАН РАЙОНЫНДА

Үтәлүне тикшерү эше партия эшенең нигезе. Партия оешмасы дөрес карар чыгару белән бергә, аның үтәлешен дә системалы рәвештә тикшереп торырга, карарларның тулы һәм төгәл үтәлүләрен тәэмин итәргә тиеш. Партиянең Бауман райкомында нак менә шушы сыйфат җитеп бетми. Райком бюросы аерым оешмаларның эшләренә карата бик яхшы карарлар кабул итә. Ләкин үтәлешне тикшерү тиешле югарылыкка куелмаганлыктан, ул карарларның шактый өлеше үтәлмичә калалар. Райком секретаре иптәш Сугановның отчет - доклады буенча чыгып сөйләүче делегатлар райкомның күп кенә уңышларын күрсәтү белән бергә, күбрәк менә шушымәсьәләгә тукталдылар.

— 1938 нче елның март аенда райком бюросы безнең оешмага карата бик яхшы карар кабул иткән иде,—ди Наркомпрос янындагы партоешма секретаре иптәш Леванова,—ләкин бу карар Наркомпростагы барлык коммунистларга түгел, хәтта бюро членнарына да җиткерелмәде. Кыскача әйткәндә, карар үтәлмичә калды, ә райком җитәкчеләре үзләре чыгарган карарның үтәлешен тикшермәделәр.

Казан Авиация институты директоры иптәш Шухов үзенең чыгышында шундый бер мисаль китереп үтте: Бауман райкомы махсус бригада җибәреп, институтның эшен тикшерткән һәм бу бригада атна буе утырып бай материал туплаган. Институт җитәкчеләре райком бюросыннан карар көткәннәр. Ләкин бу карар булмаган. Ә инде 3 ай үткәннән соң институтка райкомнан икенче бригада килгән һәм элекке бригада тарафыннан күрсәтелгән җитешсезлекләрнең ничек бетерелүен сорый башлаган. Фактта исә элекке бригада берниндә дә күрсәтмә бирмәгән булган. Шулай итеп озак вакытлар тикшерелгән эш нәтиҗәсез калган.

Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты янындагы партоешма секретаре иптәш Завьялов, Камиль Якуп исемендәге типография директоры Әхмәдуллин иптәшләр дә шуңа ошашлы фактлар китереп үттеләр һәм райкомның үтәлүне тикшерү эшләрен тиешле югарылыкка куярга кирәклеген күрсәттеләр.

Райкомның икенче зур кимчелеге итеп, башлангыч партоешмаларга конкрет булышлыкның җитәрлек булмавы күрсәтелде. Чыгып сөйләүчеләрдән Зәбиров, Кәримов, Малюгин һәм Левшин иптәшләр бу мәсьәләгә аеруча тукталып үттеләр. 28 нче февральдәге иртәнге һәм кичке утырышларда отчет буенча сөйләүләр дәвам итте. Бүген райком составына сайлаулар була.

М. Ш.

МОЛОТОВ РАЙОНЫНДА

Молотов районы большевиклары райкомның эше турындагы отчет-докладын гаять зур күтәренкелек белән тикшерәләр. Фикер алышуларда катнашучы иптәшләр райкомның уңышлы якларын күрсәтү белән бергә, практик эштә булган җидди кимчелекләрне каты тәнкыйть уты астына алалар.

Молотов районы — ВУЗ лар районы дип, бик урынлы атала. Биредә политик һәм теоретик яктан хәзерлекле, бөек Ватаныбызга чын күңелдән бирелгән белгечләр хәзерләнә. Партиянең Молотов райкомы моны истә тотып, партиянең ВУЗ лардагы оешмаларына җитәкчелекне һәм студентлар арасында политик-тәрбия эшләрен шактый яхшырткан. Шуның белән бергә, бу өлкәдә зур кимчелекләр дә бар әле.

— Марксизм-ленинизм кафедраларына кадрлар сайлап алу һәм аларны тәрбияләү эшеннән райком күп вакытта читтә тора. Яш кадрлар җидди ярдәм көтәләр, ә райком аларны җыеп беседалар үткәрми, ди иптәш Арнаутов.

Иптәш Нежданов коммунистларның укуда авангардлык рольләренә туктап, кайбер саннар китерә. Медицина институтында укучы коммунистларның бары тик 55 кенә проценты үткән экзамен сессиясендәге зачетларны отлично һәм яхшы билгеләренә тапшырды. 6 коммунист зачетны бөтенләй тапшырмады.

„Спартак“ комбинаты Молотов районында иң зур предприятиеләрнең берсе. Райкомның комбинат партоешмасына җитәкчелек эшен яхшырту аркасында, „Спартак“ комбинаты үткән елгы планны тулысынча үтәүгә иреште. Ул гына да түгел, комбинат дәүләт алдындагы ике еллык бурычын да түләүгә ирешә. Уңышларга ирешү өчен көрәштә комбинатның коммунистлары алгы сафта булдылар.

— Әгәр дә, — ди иптәш Корбанов, — быелгы җиңү саннары артынданиләр ятканын райком тирәнтен тикшергән булса, ул, һич шиксез, күңелсез фактларны да күргән булыр иде. Стахановчылык хәрәкәтенең яңа формалары комбинатта киң рәвештә җәелми. Хезмәткә коммунистик караш мәсьәләләре белән партия оешмасының тиешенчә шөгыльләнмәве аркасында хезмәт дисциплинасы йомшак. Промышленность предприятиеләре янындагы партоешмаларга райкомның канәгатьләнерлек җитәкчелек итмәве турында иптәш Исмагыйлова да бик ачык әйтте.

Кичә иртәнге һәм кичке утырышларда фикер алышулар дәвам итте.

Р. Бәһау.



Сталин районы коммунистларының 15 нче партконференциясе делегатл ары ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Штиннең отчет докладын тыңлыйлар.

И. Галиев фотосы.

СТАЛИН РАЙОНЫНДА

ВКП(б) ның Сталин район конференциясе делегатлары райкомның отчет докладын зур игтибар белән тыңладылар һәм фикер алышуларда актив катнаштылар.

Партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан куелган хуҗалык-политик бурычларны үтәү буенча партиянең район оешмасы шактый эшләр башкарган. Дәүләт промышленносте буенча 1939 нчы ел планын 105,5 процент, промартельләр буенча 118 процент итеп үтәүгә ирешелгән. Шулай да әле районда производство планын тулы үтәмәүче аерым предприятиеләр („Искож“ заводы, Энергокомбинат) бар. Тимер юл транспорты һәм автотранспорт эшенең торышы да канәгатьләнерлек түгел.

ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Штин үзенең докладында хуҗалык бурычларын үтәү буенча булган уңышлар һәм аерым кимчелекләр турында шактый сөйләде. Ләкин предприятие администрациясенең эшенә контрольлек итү ничек куелган, бу өлкәдә кайсы оешманың нинди тәҗрибәсе һәм кимчелеге бар, менә болар турында докладчы конкрет бер нәрсә дә әйтмәде.

Иптәш Штин ВКП(б) сафларына кабул итү, яш коммунистлар белән эшләү, яңа кадрлар үстерү, районда партпропаганданың торышы мәсьәләләренә тукталып, күп кенә мисальләр китерде. Отчет чорында партиягә 477 кеше член итеп һәм 1.042 кеше кандидат итеп кабул ителгән. Җитәкче эшләргә 1.861 кеше күтәрелгән. Районда 5 меңнән артык кеше ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнә. Ләкин әле яш коммунистларны тәрбияләү, кадрларга булышлык күрсәтү һәм партия пропагандасының сыйфаты өчен көрәш җитәрлек түгел. Доклад буенча фикер алышуларда катнашучы делегатлар бу мәсьәләләр буенча җидди кимчелекләрне күрсәтеп үттеләр.

— Бездә, Ильич исемендәге механический заводта,—ди иптәш Антипин,—райком работниклары бер дә булганы юк. Райком стахановчыларны партиягә кабул иткән вакытта гына белеп кала. Пропаганда һәм агитация эшенең сыйфатын яхшырту өчен көрәш йомшак. Бу эшне пропагандистларга һәм агитаторларга тапшыру белән генә чикләнелә.

Иптәш Кузьмин (Мехкомбинат) аерым коммунистлар белән эшләүгә, партдисциплинаны ныгытуга, цех партоешмаларының эшенә аз игтибар бирелүен әйтте. Ул, райком җитәкчелегенә тукталып, болай ди:

— Райком тарафыннан башлангыч оешмаларга дифференциаль җитәкчелек күрсәтелми. Барлык секретарьларны райкомга чакыралар да, гомуми установка биреп җибәрәләр. Райком бүлекләренең һәм инструкторларның оператив эше йомшак. Райкомга килеп керсәң әле берсе, әле икенчесе маглумат сорап аптырата. Алар күбрәк техник эшләрне башкаручылар булып киткәннәр. Менә мондый эш стилен бетерергә кирәк.

Фикер алышуларда катнашучы Хөсәенова, Кузнецов, Ерин, Биктимиров, Осипов һәм башка иптәшләр җитәкче эшләргә күтәрелгән кадрларга ярдәм күрсәтү, партия хуҗалыгын алып бару өлкәсендәге, массовый оборона эшендәге кимчелекләрне күрсәттеләр һәм эшлекле такдимнәр керттеләр.

У. Ахметов.

КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ РАЙОНЫНДА

Кызыл Йолдыз районы коммунистларының район җыелышы зур күтәренкелек белән ачылды. Райкомның эше турында райком секретаре иптәш Юсупов отчет-доклады белән чыкты.

Отчет чорында районда партия оешмалары иң яхшы кешеләр хисабына үскән. Партиянең XVIII нче съездыннан соң ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 130 кеше, член итеп 43 кеше кабул ителгән. Партиягә яңа кабул ителүчеләр арасында: Усали авылы тулы булмаган урта мәктәп директоры орденлы Абдуллин, „Трактор“ колхозы председателе һәм район советы депутаты Хәйруллин иптәшләр бар. Отчет чорында җитәкче постларга 111 кеше күтәрелгән.

Бүген отчет доклады буенча фикер алышулар башланды.

Мәҗитев.

ШИРӘМӘТ РАЙОНЫНДА

27 нче февральдә район культура йортында Ширәмәт районы коммунистларының VI нчы партконференциясе ачылды. Конференциягә тавыш бирү хокукы белән 73, киңәш бирү хокукы белән 10 делегат катнаша.

Райком секретаре иптәш Марков отчет доклады ясады. Аннары ревизия комиссиясенең доклады тыңланды.

Отчет чоры эчендә районда 12 яңа башлангыч оешма һәм 4 кандидатлар группасы төзелгән. Партиягә член һәм кандидат итеп 190 кеше кабул ителгән. 63 кеше җитәкче эшләргә күтәрелгән.

28 нче февральдә конференциядә ВКП(б) райкомының һәм тикшерү комиссиясенең отчет-докладлары буенча фикер алышулар дәвам итте. (ТатТАСС).

ЧИСТАЙ РАЙОНЫНДА

Партиянең Чистай район конференциясе зур активлык белән бара. ВКП(б) райкомының эше турында райком секретаре иптәш Әбләлимовның отчет - докладына буенча фикер алышуларда 44 кеше катнашты. Чыгып сөйләүче делегатлар райкомның эшендәге аерым уңышларга тукталу белән бергә, райкомның җитәкчелегендәге яраксыз практиканы большевистик тәнкыйть уты астына алдылар.

Райком, партияле һәм партиясез кадрлар үстерү һәм тәрбияләү турында ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыру эшен тиешенчә оештырмаган. Коммунистларның идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү эше йомшак тора. Партиянең күп кенә оешмаларында „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ н өйрәнү эшенә җидди игтибар бирелми. Мәсәлән, Шәһәр Советы янындагы башлангыч партоешма коммунистларының 60 проценты ВКП(б) тарихының I һәм II нче бүлекләрен генә өйрәнгәннәр. МТС, „Красный двигатель“ заводы, элемтә бүлеге һәм „Швейнник“ артеле янындагы партоешмаларда коммунистларның күпчелеге үзләренең теоретик артталыкларын бетерү өстендә кирәгенчә эшләмиләр. Партиянең район активы арасында да бу эшнең торышы канәгатьләнерлек түгел. Райком секретарьлары Әбләлимов, Завьялов һәм бюро члены Жуков иптәшләр ВКП(б) тарихын III-IV нче бүлекләрен генә өйрәнгәннәр.

Делегат иптәш Баринов кадрларны сайлап алу һәм аларга ярдәм итү буенча булган кимчелекләрне ачып салды. Теге яки бу участкыга җаваплы эшкә күтәрелгән кадрларга системалы ярдәм оештыруга җидди игтибар бирелми. Мәсәлән, Мөслим МТС ы директоры Сафин, „Красный двигатель“ заводы партоешмасының секретаре Нурыттинов, шәһәр сәламәтлек саклау бүлеге мөдире Матвеева иптәшләрне алырга була. Бу иптәшләргә райком тарафыннан вактында практик ярдәм күрсәтелмәгән. Нәтиҗәдә, райком аларның эшләрендәге кимчелекләрне ныклап тикшермичә, „эшли алмыйлар“ дип эшләреннән алган.

Райком җитәкчеләре үзләре чыгарган карарларның үтәлешен тикшерү белән шөгыльләнмәгәннәр. Районда МТС эше турында 1939 нчы елны 6, Булдырь нефте разведкасы турында 4, культура һәм хуҗалык эшләре буенча уннарча карарлар кабул ителгән. Ләкин карарларның күбесе үтәлми калган.

Конференция райкомның эшен канәгатьләнмәслек дип тапты һәм практик эштәге кимчелекләрне бетерү буенча конкрет карар кабул итте.

К. Исламов.

ӘЛМӘТ РАЙОНЫНДА

ВКП(б) ның Әлмәт район конференциясе ачылды. Райком секретаре иптәш Бикбов отчет-докладны ясады. Докладчы, җәмагат терлекчелеген үстерү планының арттырып үтәлүен күрсәтеп үтте.

Ләкин райкомның эшендә җитешсезлекләр дә күп. Райкомның авыл хуҗалыгына җитәкчелеге канәгатьләнерлек түгел. Югары уңыш өчен, дәүләт тарафыннан куелган бурычларны үтәү өчен көрәшкә колхозчылар массасы җитәрлек тупланмаган. Узган елны язгы чәчүгә хәзерлек эше тәэмин ителмәү нәтиҗәсендә, районда уңыш түбән булды һәм күп кенә колхозлар дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үти алмадылар. Райком бу җидди кимчелекләрдән үзенә тиешле нәтиҗә ясамаган. 1940 нчы елның язгы чәчүенә хәзерлек эшенең торышы моны ачык күрсәтә. Орлык хәзерләү һәм аны тиешле конденциягә җиткерү, кышкы агрономия чараларын тормышка ашыру гафу ителмәслек начар тора.

ВКП(б) райкомы партия сафларын үстерү һәм яш кадрларны тәрбияләү өлкәсендә күп кенә эшләр үткәргән. Отчет чорында ВКП(б) га член итеп 100 кеше һәм кандидат итеп 143 кеше кабул ителгән. 12 урында партиянең башлангыч оешмасы һәм 13 урында кандидатлар группалары оештырылган. Яңа оештырылган партоешмаларның күпчелеге колхозлар янында. Ләкин төп профессия работникларыннан алдынгыларны партиягә алу эшенә игтибар биреп җиткерелмәгән. Тракторчылардан һәм комбайнчылардан партия сафларына бер генә кеше кабул ителгән.

Фикер алышуларда чыгып сөйләүче иптәшләр партия пропагандасының куелышы канәгатьләнерлек булмавын ачып салдылар. Райком бюросы,—ди иптәш Шакиров,—партия пропагандасы белән җитәрлек шөгыльләнмәде.

Конференциядә фикер алышулар зур активлык белән бара.

З. Салахеттинов.

ФОРМАЛЬ КАРАШНЫҢ КҮҢЕЛСЕЗ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Республикабызны тоташтан грамоталы республика итү бурычы партия һәм совет оешмалары алдында торган мөһим бурычларның берсе һәм Татарстанның егерме еллык бәйрәменә без бу бурычны хәл итеп чыгарга тиешбез. Моның өчен бездә барлык мөмкинлекләр бар, тик, кызганычка каршы, аерым урыннарда бу бурычның җиддилеген төшенеп җитәргә генә теләмиләр. Арча районы работниклары моның ачык мисале булып торалар.

Дөрес, моннан күп көннәр элек, Арчада бу мәсьәләне бер кат „куеп караганнар“, хәтта укый-яза белмәүче һәм аз укый-яза белүче кешеләрнең саннарын да алганнар, хәтта бу санның бик зур булуын күреп бик нык гаҗәпләнгәннәр дә. Ләкин эш шуннан ерак китмәгән, шаулаганнар-шаулаганнар да, онытканнар. 1939 нчы елның беренче декабренә алынган саннарга караганда, Арча районында укый-яза белмәүчеләр 1.633, аз укый-яза белүчеләр 2.258 кеше. Шуның өстенә тагын яңа алфавит буенча 7.887 кеше яңадан укытып чыгарылырга тиеш. Болар—1939 нчы елның 1 нче декабренә алынган саннар. Ул вакыттан бирле инде күп кенә кар яуды һәм ул вакыттан бирле Арча районы работниклары бу саннарның зурлыгына гаҗәпләнми башларга өйрәнделәр.

Район буенча бүгенге көндә төгәл сан юк, аны РОНО дан да, райбашкарма комитетыннан да табып булмый. Райком да, райсоветның башкарма комитеты да бу мөһим эшне бөтенләе белән РОНО карамагына тапшырып, үзләре тынычланып калганнар. Райбашкарма комитеты председателе иптәш Шәмсеттиневкә бу турыда сорау биргәч, ул әллә ни аптырап тормыйча, „аның белән РОНО шөгыльләнергә тиеш“ дип кенә җавап кайтара. Ә РОНО да исә күбесе яңа работниклар, алар эшнең кайсы башыннан башларга белмичә аптырап торалар. Күп кенә вакыт РОНО да зурларны укыту буенча инспектор да булмыйча торган, хәзер инде ул бар, ул үзе белгәнчә эшләп тә ята, ләкин ул яңа һәм яш работник, аңа һәр яклап ярдәм итәргә, булышырга кирәк, ә чынлыкта исә әнә шул эшлекле ярдәм юк, яш работникның эше белән кызыксынмыйлар.

Моннан бер-ике ай элек, бу турыда бик күп сүзләр йөргәннән соң, ВКП (б) райкомы бу мәсьәләне үзенең бюро утырышына куеп, артта баручы ике авылның—Төбәк - Чокырча һәм Секертән авыллары партоешмалары секретарьларының информацияләрен тыңлаган. Тыңлаган һәм карар кабул иткән. Карар кабул иткән һәм... оныткан. Төбәк-Чокырча авылында укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенең торышы бүгенге көндә дә һич тә мактанырлык түгел. Авылда 114 кеше укырга тартылмаган, хәзерге көнгә чаклы зурлар мәктәбе мөдире булдырылмаган, райком бюросының карары үтәлми. ВКП (б) райкомы үзенең бу авыл һәм аның конкрет работниклары турында чыгарган карарының тормышка ашырылуын бер тапкыр да тикшермәгән.

Райкомның беренче секретаре иптәш Бәдреттинев: „Дөресен әйтим, мин ул эшкә оператив җитәкчелек итә алмыйм, ул мәсьәлә белән райкомның 3 нче секретаре иптәш Шаһиева шөгыльләнә“ ди. Без иптәш Шаһиевага мөрәҗәгать итәбез, иптәш Шаһиева җавапка шулай ук күршегә керми. „Ул эш буенча РОНО да махсус кеше утыра, оператив җитәкчелекне ул кайгыртырга тиеш, безнең оператив җитәкчелек итәргә тиешле эшләребез болай да җитәрлек“ дип кенә җибәрә: Бәлки без иптәш Шаһиеваның кәефсез чагына туры килгәнбез, ләкин аңа карап кына эш җиңеләйми!

Факт ачык: райком бу мөһим эшкә җитәкчелек итми, эшне, „Гали—Вәлигә, Вәли—Галигә“ тапшырганнар да, үзләре тынычланып калганнар.

Район Советының башкарма комитеты турында да шуннан да артыкны әйтеп булмый. Алар да бу мәсьәләне бер тапкыр президиум утырышында карап, бурычны „өсләреннән төшергәннәр“ дә, инде тәмам онтырга да өлгергәннәр. Моннан бер ай элек, райбашкарма комитеты президиумы Зур Бирәзә авылында зурларны укыту эшенең торышын бик начар дип таба. Зур Бирәзә авылының уку өе мөдире Корбановны президиум үзенең карарында „зурларны укыту эшеннән бер нинди сәбәпсез кача, эшләми“ дип теркәп үтә. Карар чыга, аны карарлар папкасына бик әйбәтләп теркәп тә куялар. Зур Бирәзә авылы үзенең урнында кала, шулай ук сүз тыңламый торган Корбанов та үзенең урнында кала, тик эш кенә күренми. Арча работниклары „без мәсьәләне куйдык“ дип үзләрен тынычландыра торганнардыр, дөресен әйтергә кирәк, бу—мәсьәләне кую да, хәл кылу да түгел, бу—бары тик мәсьәләгә формаль караш кына.

Укый-яза белмәүчелекне бетерү эшендә комсомол гаять зур эшләр эшли ала һәм ул эшли дә. Кызганычка каршы, Арча районының комсомол оешмасы турында моны әйтеп булмый. Монда укый-яза белмәүчелекне бетерү эшенә күңел куеп тотынмаганнар һәм шуңа күрә эш тә бармый. Шушы көнгә чаклы ВЛКСМ райкомының бюросында бу мәсьәләнең бер генә тапкыр да куелып тикшерелмәве үзе генә дә иптәшләрнең бу эш белән кызыксынмауларын күрсәтә. Допризывниклардан, яш егетләр һәм яш кызлар арасыннан укый-яза белмәүче иптәшләр булуы комсомолның Арча район оешмасы работникларын аз гына да борчымый. Шулай ук сүз тыңламый торган Корбановлар һәм аның ишеләр турында да, оешмага тап төшерүче мондый комсомолецлар турында да уйларга бик мөмкин булыр иде.

Арчада рус һәм татар телендә ике газета чыгып килә. Тик бу ике газета икесе дә укый-яза белмәүчелекне бетерү буенча бер нәрсә дә эшләмиләр дип әйтерлек. Татар телендә чыга торган „Яңа Тормыш“ газетасы 1940 нчы елны кечкенә ике информацион хәбәр урнаштыру белән чикләнеп калган. Редактор иптәш Рамазанов та, райкомның 3 нче секретаре Шаһиева иптәш биргән җавап төслерәк җавап бирә: „кампанияләр бик күп, кайсын гына яктыртып бетерәсең соң“ ди. Эш күплекне сылтау итеп эшсез ятуны нәрсә белән аңлатырга кирәктер? Һәр хәлдә районның башка җитәкче работниклары белән бер рәттән газета редакторлары да бу турыда уйларга тиешләр.

Районның җитәкче работниклары әле тегене, әле моны сәбәп итеп бу мөһим бурычтан читләшергә теләсәләр дә аерым авылларда укый-яза белмәүчелекне бетерү эшендә күңел биреп эшләүче, инициативалы работниклар юк түгел, әлбәттә. Җитәкчелекнең йомшак булуына да карамастан, алар бу эштә тырышып эшләп киләләр. Мәсәлән, Наласа авылында яңа алфавит буенча 74 кеше укып чыкты һәм экзамен бирде, калганнары да тырышып укып яталар. Яки менә икенче бер күңелле фактны алып карыйк. Без шунда, РОНО йортында, зурларны укыту эшенең барышыннан зарланып үзара сөйләшеп торган чакта, салкыннан бит алмалары кызарган һәм керфекләре бәсәргән яшь бер кеше килеп керде. Бу—Күлтәс авылы укытучысы иптәш Фатыйхов. Ул укый-яза белмәүчеләрне укыту мәктәбен тәмамлап чыккан 95 кеше өчен акт алып килгән. Ул үзенең культармеецләре белән мактанып сөйли һәм ул, бу эш буенча безне бер дә җыймыйсыз, тәҗрибәләрне уртаклашмыйсыз, дип РОНО работникларына үзенең үпкәсен белдерә.

Төберчәк авылы башлангыч мәктәбе укытучысы Фәсәхәт иптәш Шәрифуллина 15 кеше укытып чыгарган, хәзер 38 кешене укыта. „8 нче Март бәйрәменә чаклы боларын да укытып чагарырга сүз бирдем, сүземдә торырмын дип уйлыйм“ ди иптәш Шәрифуллина.

Мондый тырыш иптәшләр районда күп кенә һәм алар чын күңел белән тырышып эшләп яталар. Бары тик алдынгыларның тәҗрибәләрен оештыручы гына юк. Шушы көнгә чаклы РОНО да зурларны укыту буенча бер генә тапкыр да киңәшмә уздырылмаган. Эшләгән кешеләрне дә, эшләмәүчеләрне дә күрмиләр, көн артыннан көн үтә, кыш артыннан җәй килә, укытучылар үз урыннарында, ә РОНО работниклары үз урыннарында әкерен генә тора бирәләр.

Җыеп кына әйткәндә шул: Арча районында зурларны укыту эше гафу ителмәслек начар хәлдә калган. Районны бу хурлыклы хәлдән чыгару өчен районның җитәкче оешмалары барлык чараларны күрергә тиешләр. Ә беренче чиратта алар үзләре турында уйларга, үзләренең онытучанлыкларын бетереп, бу эшкә большевистик җитәкчелекне булдырырга тиешләр.

Фатыйх Хөсни.

ФИНЛЯНДИЯ ВАКЫЙГАЛӘРЕНЕҢ ХАЛЫКАРА ХАРАКТЕРЫ

(БАШЫ КИЧӘГЕ НОМЕРДА)

СССР ГА КАРШЫ КЕМ ҺӘМ НИ ӨЧЕН СУГЫШ ОЕШТЫРЫРГА ТЕЛИ

СССР белән Германия арасында һөҗүм итешмәү турындагы договор гына түгел, бәлки дуслык турындагы договор да барлыкны, Германияне англичаннар һәм французлар теләгәнчә тиз буарга мөмкин түгеллекне, Советлар Союзының Көнбатыш Украинаны һәм Көнбатыш Белоруссияне капиталистлардан һәм алпавытлардан азат иткәнлеген һәм Советлар Союзының Англия—Франция политикасына бәйсез булган аерым политика алып баруын англичаннар һәм французлар әле һаман да аңларга теләмиләр. Англичаннар — французлар һәм американылар 20 ел буена Финляндияне СССР га каршы хәзерләп килгәнлекләрен, бу эшкә күп акча тотканлыкларын һич тә оныта алмыйлар. Кинәт аларның бөтен сугыш интервенциясе планнары катыргыдан ясалган йорт кебек җимерелә. Ачуланырлык урында бар шул.

Финляндия хуҗалыгының төп тармагы—урман байлыкларын эшкәртү—„Финляндия урман промышленносте берләшмәсе“ кулында тупланган. Бу берләшмә флагы астында Англия капиталы эш итә. Бу берләшмәгә керә торган акцияле җәмгыятьләр 1937 нче елны 8,6 миллиард маркалык продукция эшләп чыгардылар. Бу—илнең бөтен агач-кәгаз продукциясенең 96 проценты дигән сүз. Финляндиядән Англиягә чыгарыла торган барлык товарларның 50 проценты агач материаллары.

Петсамодагы иң кыйммәтле рудникларны эшкәртү Монд-никель исемле Англия—Канада компаниясенә 40 елга бирелгән. Бу районда 7 миллион доллардан артык капитал салынган.

Финляндиядә Англия—Америка капиталы ярдәме белән сугыш предприятиеләре төзү башланды. 1937 нче елны Таммерфорста беренче буларак сугыш авиациясе заводы эшли башлады, 1939 нчы елның башында Ивесткюлюда орудиеләр заводы ходка җибәрелде: автомобильләргә монтаж һәм ремонт ясау буенча ремонт мастерскойлары төзелде.

„Юнайтед Вюллен Миллс компани Лимитед“ концернының Хювинкя шәһәрендә (Хельсинкидән 30 миль төньяктарак) Төньяк Европада иң зур фабрикалардан булган йон фабрикасы бар.

Промышленность концерыннарына ссудалар биргән Индустриаль банкның барлык акцияләренең яртысы Англиядә урнаштырылды (банкның капиталы—4 миллион фунт стерлинг).

Муниципаль банк капиталының да өчтән ике өлеше Англиядә урнаштырылган.

Ниһаять Финляндия дәүләт банкысының күзәтү советы председателе Таннер һәм аның директоры, ак фин „премьер“ Рюти турыдан-туры Англия банкысы агентлары иде. Бу соңгысы чит ил капиталы каршында күрсәткән хезмәтләре өчен Англия короле тарафыннан Англия дворянины исемен алды.

АКШ ның финанс группалары, мәсәлән, „Браун Бразерс“, „Браун Гарримэн компани“ Финляндиядә кыйммәтле кәгазләр чыгаруда ярдәм иттеләр. „Нейшенэл сити Бэнк“ Финляндиянең урман промышленникларына зур кредитлар бирде.

Капитал чыгаруны тикшерүче американлы Льюис „Американың халыкара капитал салулары“ дигән китабында 1935 нче елны американлылар кулында Финляндиянең 32 миллион долларлык кыйммәтле кәгазләре булганлыкны күрсәтә.

Язучы Росестер „Американың хуҗалары“ исемле китабында „Интернейшенел телефон энд телеграф компани“ ның (Морган компаниясе) Швециянең „Эриксон“ фирмасы белән берлектә (бу фирма да шактый дәрәҗәдә Морган контроле астында яши) Финляндиядә телефон челтәрен үз кулларына алып бетергәнлекләрен хәбәр итә.

Швециянең шырпы концерны башында Крейгер торган чорда Финляндиядә бу концернның зур дүрт шырпы фирмасы бар иде. Бу фирмалар илдәге бөтен продукциянең өчтән ике өлешен бирәләр иде. Финляндиянең шырпы эшләүче кооператив фабрикалары концерннан тыш яшиләр иде. 1927 нче елдан башлап алар да Крейгер картеленә буйсындылар. Крейгер концернының банкротлыкка төшүе Валленберг группасын көчәйтте. Бу группа Швеция капиталының Валленберг группасы кулына гына тагын да ныграк туплануына китерде.

Бөтен дөньяга киң маглүм булган һәм зурлыгы ягыннан Американың „Интернейшенел телефон энд телеграф компани“дан һәм Германиянең Симменс компаниясеннән генә калыша торган телефон, телеграф һәм радио тресты „М. М. Эриксон“ Финляндиядәге бөтен телефон челтәренә хезмәт күрсәтә.

Финляндиянең палач Маннергеймда гәүдәләнә торган гүзәл „демократиясе“ уңае белән англичаннарның, французларның, американлыларның гуманитар һәм идеалистик фикерләрен бу саннар һәм фактлар бигрәк тә ачык аңлаталар.

Көнбатыш Украинаның һәм Көнбатыш Белоруссиянең СССР га кушылуын һәм СССР ның Көнбатышка якынаюын англичаннар һәм французлар зур борчылу белән кичерделәр. Хәзер инде аларның әгәр Финляндиядә Рюти—Каяндер—Таннер шайкасы урнына чын демократик хөкүмәт урнаштырылса нәрсә булыр дип котлары чыга.

Дуслык һәм туганлык турында СССР белән Финляндиянең Халык Хөкүмәте арасында төзелгән договорның чит ил капиталистлары доходларына кагылачагын уйлап англичаннарның һәм французларның котлары оча. Билгеле, ул шулай булачак та. Ллойд Джордж үзенең 20 нче февральдәге соңгы мәкаләсендә болай дип язган иде: „Англиянең һәм Франциянең эш башында утыручы сыйныфлары милләтче-социалистлар Германиясенә каршы сугыш белән кызыксынуга караганда большевистик Россиягә каршы сугыш белән күбрәк кызыксыналар“. Һәм ул бик хаклы.

ФИНЛЯНДИЯДӘ ИКЕ ХӨКҮМӘТ

Тарих ике властьлылыкның бик күп мисальләрен белә.

Безгә билгеле булган иң соңгы мисаль—ул, Испаниядәге гражданнар сугышы һәм ике властьлылык. Ул чагында генерал Франко башка империалистик державалар (Англия, Франция, Италия һәм башкалар) ярдәме белән Испаниядә законлы демократик хөкүмәткә каршы баш күтәрде. Финляндиядә бара торган вакыйгалар Испаниядәге вакыйгаларга ошыйлар. Ләкин тискәре ягы белән. Финляндиядә власть башында ак гвардеецларның ярым бандит хөкүмәте тора, Советлар Союзы ярдәме белән азатлык көрәше алып баручы халык бу хөкүмәткә каршы баш күтәрде.

Финляндиянең Халык Хөкүмәте үзенең типы һәм характеры ягыннан Испаниядәге халык фронты хөкүмәтенә якын тора. Негрин хөкүмәте һәм Куусинен хөкүмәте—алар чын магнәсе белән демократик халык власте. Испаниядә һәм Финляндиядә республикалар формаль демократия нигезендә түгел, бәлки алпавытларның җирләрен крестьяннар файдасына конфискацияләү һәм эре частный банклар һәм промышленность предприятиеләре өстеннән дәүләт контроле урнаштыру нигезендә төзелделәр.

Бу ике властьлылык шартлары Финляндиянең үзендә һәм чит илләрдә бара торган вакыйгаларга аерым төс бирә, чөнки Куусинен җитәкчелегендәге хөкүмәт, ул—халык эченнән чыккан хөкүмәт, Финляндиядә бөтен тормышны халык өчен һәм халык интересларын күздә тотып оештырырга хәзер торучы хөкүмәт. Халыкара капиталның котырынуы һәм фин ак гвардеецларының акылсыз чыгышлары шуннан килеп чыгалар.

Ак Финляндия хөкүмәтенең эчке политикасы нинди соң? Ул йөз меңнәрчә эшчеләрне, крестьяннарне яши торган урыннарыннан куа, ә халыклар үз өйләреннән китүдән баш тартканда, шюцкорчылар аларның йортларын яндыралар һәм протест белдерүчеләрне атып үтерәләр.

Ак гвардеецлар үзләренең позицияләрен Совет гаскәрләре һөҗүме астында калдырып, Финляндия хезмәт ияләренә бер нәрсә дә калмасын өчен заводларны, фабрикаларны яндыралар, машиналарны ваталар, товар запасларын юк итәләр. Ак Финляндиядә һич ишетелмәгән террор хөкем сөрә, йөзләрчә кешеләр судсыз һәм тикшерүсез атып үтереләләр. Кечкенә генә ризасызлык өчен дә аталар, шуның белән бергә приговорларның сәбәбе һәр вакыт бер төсле була: чит ил дәүләте файдасына шпионлык. Финляндиянең Халык Хөкүмәтенә теләктәшлек күрсәтүче кешеләр, яши торган урыннарыннан китәргә теләмәүче кешеләр, ак гвардия режимына каршы сөйләүчеләр, маннергеймнарның һәм капиталистик дөньяның башка геройларының демократик турылыклыларына шикләнүче кешеләр шушы категориягә кертеләләр. Риза булмаганнарның барсы өчен дә бер генә җавап—ату.

Чит ил матбугатына кыенлык белән генә үтеп кергән хәбәрләр Финляндиядәге зур ризасызлыкларны күрсәтәләр. Бу ризасызлык армияне дә чолгап алган. Бу турыдагы хәбәрләр хәтта буржуазия газеталарына да үтеп керәләр. Швеция һәм Норвегия матбугаты: „Шпионлык“ өчен күптән түгел генә 60 солдат атылды“ дип яза.

Халык Хөкүмәте нәрсә соң ул һәм илдә аның таянычы бармы?

1918 нче елгы революция бастырылганнан соң коммунистлар Финляндия профсоюзларында берничә тапкыр зур күпчелек алдылар, ләкин һәр вакытта да полиция профсоюзларны япты, ә социал-демократлар шунда ук үзләренең профсоюз оешмаларын төзеделәр, аларга революцион эшчеләрне кертмәделәр. Төрмәләр коммунистлар һәм сул эшчеләр белән тутырылды, шулай итеп Финляндиянең эшчеләр сыйнфында социал-демократия өстенлеге тәэмин ителде.

Финляндия компартиясенә һәм сул эшчеләргә каршы репрессияләр бер минутка да тукталмады. Фин пролетарийларын рәхимсез рәвештә хөкем иттеләр, аларны төрмәләргә тутырдылар. Кыйнаулар һәм провокацияләр юлы белән полиция һәм шюцкорчылар хәзерге вакыйгалар башланганчы ук инде күп кенә революцион эшчеләрне кулга алдылар.

Вакыйгалар башлану алдыннан тирән подпольедә Финляндия компартиясендә 1.000 гә якын кеше бар иде. Безгә, күп миллионлы партиягә күнеккән кешеләргә, бу сан бик аз булып күренергә мөмкин. Ләкин мондый әйберләр абсолют саннарда түгел, бәлки чагыштырма саннарда хәл ителәләр. Февраль революциясе алдыннан большевистик партиянең 10.000 гә якын члены бар иде, бу 15.000 кешегә партиянең бер члены дигән сүз, ә Финляндиядә соңгы вакыйгалар алдыннан, 3.800 кешегә бер коммунист туры килде. Бу, компартиянең илдә тирән тамырлары бар дигән сүз.

„Советская Карелия“ газетасында һәм демократик Финляндия хөкүмәтендә чыга торган „Народная власть“ газетасында басыла торган материаллар компартиянең халык белән нинди элемтәдә икәнлеген күрсәтәләр. Ак армиядән солдатлар берәмләп һәм хәтта группалап та Халык Хөкүмәте ягына чыгалар. Шәһәрләрдә һәм авылларда исән калган халык 1 нче фин корпусын һәм Совет гаскәрләрен шатланып каршы алалар.

Шушы аз гына фактлардан да Маннергейм—Таннер хөкүмәтенең кемгә һәм нәрсәгә таянганлыгы һәм Куусинен хөкүмәтенең кемгә таянганлыгы бик ачык күренә. Хәзер инде чит илләрдә ике якны килештерү турында, Совет хөкүмәтенең такдимнәрен Рюти—Таннер хөкүмәтенең кабул итәргә хәзер торуы һ. б. турында тавышлар янгырый.

Тик бер генә нәрсә ачык, Финляндиядәге гражданнар сугышы һич тә Маннергеймның хуҗалары һәм яклаучылары теләгәнчә тәмам булмаячак. Маннергейм чит ил гаскәрләре ярдәме белән эшчеләр революциясен бер тапкыр бастыра алды инде. Ул чагында Советлар Россиясе, кардәш фин халкына карата үзенең бурычларын үтәрлек дәрәҗәдә үк көчле түгел иде. Хәзер заманалар үзгәрде. Һәм Лондонда, Парижда һәм Вашингтонда телиләрме-теләмиләрме, Финляндиядә демократик халык власте җиңәчәк.

ЙОКЫЛАРЫ КАЧКАНДА ИМПЕРИАЛИСТЛАР НӘРСӘ ТУРЫНДА УЙЛЫЙЛАР

Англия һәм Франция буржуазиясе хәзер үзләренең бөтен көчләрен СССР белән Германия арасындагы мөнәсәбәтләрне өзүгә юнәлдерәләр. Алар СССР белән Германиянең үзара талашулары турында һәм шуннан соң Германия һәм Россия халыклары аркасын каезлый алачаклары турында хыялланалар.

Икенче яктан, СССР ны Япония белән сугыштыру өчен омтылышлар бар. Узган елның ахрында без күп кенә мәсьәләләр буенча Япония белән килешүгә ирешкәч, Англиянең, Франциянең һәм Кушма Штатларның нинди ризасызлык белдергәнлекләре маглүм бит.

Япония империалистлары да Европада сугышның өзлексез баруы турында хыялланалар. Европада сугыш ни кадәр озак дәвам итсә, Япония өчен шул кадәр яхшырак булыр дип уйлыйлар. Мәсәлән, Европадагы сугыш уңае белән, Япониянең „Хони“ газетасы менә нәрсә яза:

„Европада сугыш башлану Япония өчен алланың ярдәменнән башка бер нәрсә дә түгел. Ләкин алла җибәргән бу ярдәм мәңге дәвам итәр дип уйларга ярамый. Япониянең хәрәкәтләре бу ярдәмне арттыра алган кебек аны бөтенләй туктата да алыр“.

Шул ук газета берничә көннән соң (28 нче декабрьдә) болай дип яза:

„Бу сугыш ярдәме белән без үз тарафыбыздан Көнчыгыш Азиядә урнаштырыла башланган яңа тәртипне урнаштырып бетерербез. Сугыш озакка сузылсын дип без нак менә шушы магнәдә алладан сорарга тиешбез“.

Советка каршы булган кайбер элементлар үзләренең ак финнәргә ярдәм күрсәтүләрен раса ягыннан аңлатырга маташалар. Мәсәлән, Япониянең Домей Цусин агентлыгы 1939 нчы елның 1 нче декабрендә болай дип язды:

„Япон халкының финнәргә зур игтибар бирүе шуның белән аңлатыла ки, финнәр үзләренең расалары һәм телләре ягыннан япон халкына кардәш“.

Шул ук вакытта Италиянең чит ил эшләре министре Чиано органы булган „Телеграфо“ газетасы күптән түгел генә „Финляндия төньяк герман расаларының аеруча борынгы үзәге“ дип күрсәтте.

Без бу „кардәшлек“ тойгыларына каршы килмибез, ләкин шунсы характерлы, бу кардәшлек турындагы аңлатмалар нишләптер соңгы вакыйгаларга, ягни Советлар Союзының йөрәге булган Ленинград янына урнашкан ак Финляндиянең үзенең яклаучылары ярдәме белән безнең социалистик Ватаныбызга каршы удар хәзерләгән вакытка туры китереләләр.

ХАЛЫКАРА ПРОЛЕТАРИАТ ҺӘМ ФИНЛЯНДИЯДӘ ГРАЖДАННАР СУГЫШЫ

Турыдан-туры Англия, Франция, Америка, Швеция һәм Норвегия хөкүмәтләренең котыртулары астында ак финнәр файдасына котырынган кампания башланды, шуның белән бергә бу кампания мораль ярдәм кампаниясе генә түгел, бәлки хәрби һәм материаль ярдәм кампаниясе дә. Газеталарның язуына караганда, ике ай эчендә ак Финляндия доброволецлар, кораллар, җыемнар һәм заемнар төсендә гаят зур ярдәм алган.

Акча җыю кампаниясендә халыкара социал-демократия һәм реформист профсоюз җитәкчеләренең лакейларча аеруча тырышып эшләүләре күренә. Амстердам интернационалының җитәкчеләре һәм Англия, АКШ, Швеция, Норвегия, Голландия, Швейцария, Бельгия, Франция профсоюзларының лидерлары, эшчеләрдән сорап тормастан, ак финнәргә шактый зур сумада акча җибәргәннәр һәм бу хәл членнар массасында кискен протест тудырды. Үзенең бәйсезлеге өчен көрәшкән героик испан халкына теләр-теләмәс кенә ярдәм иткән шул ук „эшче“ юлбашчылар, үз буржуазияләренә хезмәт күрсәтү өчен барлык нәрсәне эшләргә хәзер торалар.

Бу ярдәм шул кадәр ачык сыйнфи характерда ки, Маннергейм—Рюти—Таннер бандасына халык акчасын һәм эшчеләр акчасын әрәм итүгә каршы барлык илләрнең, бигрәк тә Англиянең, Швециянең, Норвегиянең һәм Даниянең намуслы эшчеләре көчле протест күтәрделәр.

Финляндиядәге вакыйгалар уңае белән халыкара эшчеләр хәрәкәтендә кискен дифференциация килеп чыкты. Әгәр дә буржуаз социал-демократик газеталарга ышансаң, эшчеләр сыйнфының иң зур күпчелеге ак Финляндия яклы дигән тәэсир калырга мөмкин. Ни өчен мондый тәэсир кала?

II нче Интернационал җитәкчеләре СССР ны һәм Куусинен хөкүмәтен кискен рәвештә гаепләделәр һәм Маннергейм—Рюти—Таннер „демократиясе“н яклап сөйләделәр. Фин халкының палачларына карата үзләренең кайнар симпатияләрен күрсәтү һәм Советлар Союзына карата үзләренең гаепләүләрен әйтү өчен Ситрин, Жуо һәм башкалар һәрбер мөмкинлектән файдаланалар. Франция, Англия, Бельгия, Швеция, Норвегия, Дания, Голландия, Швейцария, Америка һәм хәтта Германия һ. б. социал-демократик партияләренең лидерлары Финляндия „демократиясе“ нең матурлыкларын күрсәтеп шушы ук рухта бердәм рәвештә чыгалар.

Бу әфәнделәр тарафыннан әйтелгән һәрбер сүзне, II нче һәм Амстердам Интернационалларының һәрбер резолюциясен бөтен халыкара матбугат күтәреп ала. Халыкара пролетариат ак Финляндияне яклый дигән һәм Советлар Союзына каршы тора дигән тәэсир тудыру өчен халыкара матбугат тырышып-тырышып яза.

Ләкин II нче һәм Амстердам Интернационалларының җитәкчеләре, социал-демократик партияләрнең югары катлаулары—алар әле пролетариат түгел. Алар—чын магнәсе белән капиталистик эксплоатация белән бәйләнгән кешеләр, алар—социализмнан астрономик ераклыкта тора-торган кешеләр. Гильфердинглар, блюмнар белән социализм турында сөйләшү—ул, телеграф баганасына чәчәк салу белән бер.

Билгеле, халыкара социал-демократия юлбашчылары катнашы белән Советка каршы алып барыла торган бу котырынган агитация һәм пропаганда, Советлар Союзы империалистик политика алып бара дип бөтен дөнья матбугаты тарафыннан хезмәт ияләре арасында көн саен һәм бик тырышып таратыла торган фикер, хезмәт ияләренең маглүм бер өлешенең аңында билгеле бер эз калдыралар. Ләкин шулай да буржуаз социал-демократиянең берләшкән көчләре, ак Финляндия—ул „киң демократия“ иле, ә СССР фин халкының бәйсезлегенә һөҗүм итә торган ил дип халыкара пролетариатның төп массасын бер ничек тә ышандыра алмаслар.

Эшчеләр массасының чын настроениесе турында фикер йөртү өчен нинди нигезләр бар соң?

Франциядә, Бельгиядә һәм башка илләрдә компартияләрне рәхимсез эзәрлекләүгә һәм коммунистик матбугатны тыюга да карамастан, ак Финляндиянең һәм социал-демократиянең хәле начар булу турындагы хәбәрләр массага меңнәрчә каналлар аркылы үтеп керәләр.

Әйтергә кирәк, Финляндиядә сугышучы ике хөкүмәткә эшчеләрнең карашы бөтен сугыш шартларына турыдан-туры бәйләнгән. Чыннан да, сугышучы чит илләрдә хәзер хәл ничек соң?

Эшчеләр сыйнфының экономик һәм хокук хәле системалы рәвештә начарлана; налоглар гаят дәрәҗәдә үсәләр, аларның бөтен авырлыгы хезмәт ияләре өстенә төшә; барлык сугыш чаралары—көчләп куып чыгарулар, күчерүләр, беренче дәрәҗәдә кирәкле әйберләр куллануны чикләү—алар, әлбәттә, хезмәт ияләре өстенә төшәләр һәм өстен сыйныфларга кагылмыйлар. Барлык илләрдә—Англиядә, Франциядә, Кушма Штатларда, Скандинавия илләрендә—бәяләр гаят дәрәҗәдә үсә; хезмәт хакы кими; коммунистларны, компартияләрне һәм революцион эшчеләрне эзәрлекләүдә социалистларның катнашуын, компартияләрне эзәрлекләүләрнең эшчеләр массасының хәле начарлану белән бергә туры килүен гади эшчеләр дә күрәләр. Шунлыктан сугышка карата дошманлык һәм котылу юлларын эзләү үсә.

Англия һәм Франция профбюрократларының эшчеләрне котырту өчен бергә җыелулары очраклы хәл түгел. Алар үзләренең 25 нче январьда булган соңгы утырышларында, коммунистларның пропагандасы „Англия һәм Франция эшчеләр хәрәкәтенең бердәмлегенә киресенчә тәэсир итәргә“ мөмкин дип тынычсызлык белән күрсәтеп үттеләр.

Бу томанлы фраза, реакциягә каршы хәрәкәтнең куркынычлы колач алганлыгын күрсәтә. Даладьеның соңгы речендәге тревогалы ноталар һәм солдатларның арулары да шуны ук күрсәтәләр.

ШУННАН СОҢ?

Англичаннар, бигрәк тә французлар, тышкы фронтта җиңүгә ирешү мөмкинлекләре булмаса да, эчке фронтта „җиңүгә“ ирешәләр. Франциядә коммунистик партия тыелды, газеталар ябылды, партиянең милке конфискацияләнде, барлык коммунистлар парламенттан чыгарылдылар, меңнәрчә кешеләр кулга алынды; Франциягә килгән барлык эмигрантлар концентрация лагерьларына ябылды; көтепханәләрдән Горький китаплары алып ташлана.

АКШ та да реакция баш күтәрде, анда Рузвельт үзенең барлык прогрессив реформаларыннан баш тартып, котырынган реакционерларга баш иде. Дайс һәм Фиш типындагы фашистлар коммунистларга һәм СССР га каршы котки оештыралар. Компартия секретаре Браудер, үз исменә бирелгән, имештер, ялган паспорттан файдаланган өчен төрмәгә хөкем ителде.

Буржуаз демократия кимегәннән-кими бара. „Азатлык“ сугышының беренче нәтиҗәсе әнә шул. „Прогресс һәм демократия өчен көрәшүчеләр“ нең хәрәкәте әнә шундый.

Бу реакцион котырыну нәрсә белән аңлатыла? Шуның белән аңлатыла ки, эшчеләр сыйнфы сугышырга теләми һәм колонияләр өчен, Англиянең өстенлеген саклап калу өчен үзенең канын коярга теләми. Ул Франция һәм Англия колонияләрендәге йөз миллионнарча кешеләрнең моннан соң да Париж һәм Лондон биржаларының коллары булуы өчен көрәшергә теләми.

Тормышның вакытлы хуҗалары эксплоатацияләнүчеләр массасының Советлар Союзына карата мәхәббәтен беләләр. Көчсезләндерелгән Европада көчле социалистик җәмгыят яшәвендә һәм үсүендә дәвам итсә нәрсә булыр дип аларның котлары оча. Менә, Бельгиядә чыга торган зур реакцион газетаның шушы мәсьәлә буенча чиктән тыш характерлы чыгышы. „Либр Бельжик“ газетасы 24 нче январьда үзенең Париждагы хәбәрчесенең мәкаләсен басып чыгарды. Бу мәкаләдә, СССР белән дипломатик мөнәсәбәтләрне өзүнең тарафдарлары белән дошманнары арасында Франциядә кайнар полемика җәелгәнлеге күрсәтелә:

„СССР ны Германиядән соң беренче номерлы дошман дип санаргамы, яки аны Германия кебек үк куркынычлы итеп санаргамы?“.

Бу көрәш турында Париждагы төрле тенденцияләрне хәбәр иткәннән соң, хәбәрче болай дип күрсәтә: „Ләкин Франциядә тагын бер мәсьәләне оныталар—ул Европаның язмышы турындагы мәсьәлә. Әгәр дә СССР конфликттан читтә калса, һәм бер Финляндия инциденты белән генә чикләнсә, нәрсә булыр?“—„1914—1918 нче еллардагы сугыштан соң без Италиядә, Австриядә, Германиядә һ. б. да революцион көчләрнең хәрәкәтен күрдек“.—„Әгәр ул чагында алар Носке, Зейпель, Джиолитти тарафыннан буылган булсалар, әгәр ул чагында алар бетерелгән булсалар, хәзер, СССР кебек шундый революцион үзәк булган вакытта нәрсә булыр?

Төп сугышучы илләр сугыш нәтиҗәсендә көчсезләндерелсәләр, аларның эчләрендә революция өчен уңайлы шартлар тудырылса, ул чагында сугышның ахрында Европа белән нәрсә булыр соң?“

Мәкаләсенең ахрында хәбәрче болай дип яза:

„Башта шушы иблис кебек көчләрне нейтрализацияләмичә торып, тынычлык проблемасын хәл итү мөмкин түгел, бу көчләр Европа цивилизациясен юк итү өчен очраклылыкны көтеп кенә торалар“.

Хәкыйкат яш балалар авызы белән генә түгел, бәлки кайчагында революциядән куркучы һәм буржуазиягә хезмәт итүче язучылар авызыннан да әйтелә. СССР ны ничек кенә булса да сугышка тартырга теләүләре хәзер аңлашыла, дошманнарыбызның барлык махинацияләре хәзер аңлашыла. Үлем дәрәҗәсендә куркуга төшкән журналистлар барлык илләрдәге эксплоататорларның яшерен уйларын лыгырдадылар.

1918 нче елның 1 нче мартында РСФСР Халык Комиссарлары Советы һәм Финляндия Социалистик Эшчеләр Республикасы Уполномоченныйлары Советы „югарыда күрсәтелгән иреклe республикалар арасында дуслыкны һәм туганлыкны ныгыту өчен“ договор төзеделәр. 1918 нче елны фин эшчеләре революциясен тармар итү белән ертып ташланган бу кардәшлек договоры, 1939 нчы елның 2 нче декабрендә Советлар Союзы белән Демократик Финляндия Республикасы арасында үзара ярдәмләшү һәм дуслык турында төзелгән договор белән яңартылды. Дөньяда кардәш халыклар арасында төзелгән мондый корыч кебек нык договорны ерта алырлык көч юк. Заманасы ул түгел!

Ватаныбызны саклау өчен безнең үзебезнең югары сыйфатлы техник средстволарыбыз бар. Ләкин, техник средстволардан тыш безнең үз линиябез, Ленин—Сталин линиясе бар, без бу линиядә нык торабыз һәм бу линия безне бөтен дөньяда коммунизмның җиңүенә китерер.

А. ГАЛИН.

Полковой комиссар.

СОҢГЫ ПОЧТАДАН

„ИГЗӘКЛӘР“

Күз алдына Миңнегулова белән Әхтәмев иптәшләрнең очрашу картинасы килеп басты. Миңнегулованың мәсьәләне ачыктан-ачык куеп:

— Бергә булгач бергә инде, Әхтәм, нәрсәгә баш ватырга,—дип ныклап, басым ясап әйтүеннән соң Әхтәмев икеләнеп тормагандыр, мәсьәләнең ансат хәл ителүен күреп хәтта җылмаеп та куйгандыр, дип уйлыйбыз.

Әлбәттә, эшнең киресенчә дә булуы, „активлыкның“ Әхтәмев ягыннан да күрсәтелүе мөмкин. Ләкин эш анда түгел.

Укучыларыбызга әйтергә ашыгабыз: сүз әллә нинди картина турында бармый, сүз югарыда әйтелгән ике иптәшнең үзләренә тапшырылган мөһим эшне бергәләп эшләү теләге белән чираттагы килешүләре турында гына бара.

Әйтеп куйыйк: Миңнегулова—Бондюг район газетасы „Стахановчы“ның редакторы, ә Әхтәмев—Бондюг заводы газетасы „Бондюг эшчесе“нең җаваплы работнигы.

Алар һич кичектерелмәс бурыч алдында калалар. Данлыклы Кызыл Армия көне якынлашкан. Газеталарның махсус номерларын чыгарырга кирәк. Бергәләп эшләү начар эшмени? Икесе дә газета чыгаралар, икесе дә бер үк фронтта хезмәт күрсәтәләр, шулай булгач, аларның бу бердәмлеген кем гаепли алыр?

Нәтиҗәдә „Дуслык һәм үзара ярдәм“ турында менә дигән килешү, ә килешү нәтиҗәсендә газеталарның бер-берсенә тәмам охшаган игез баладай бәйрәм номерлары килеп чыга. Иң элек „Стахановчы“ газетасын ясаганнар (чөнки типографиягә дә, инициативага да ул хуҗа дип уйлыйбыз), аны басканнар, ә аннан соң аның „Стахановчы“ дигән исме урнына „Бондюг эшчесе“ дигән исем менеп утырган, аннары икенче битендә „Җаваплы редактор Н. Б. Миңнегулова“ имзасы „Җаваплы редактор өчен Г. Әхтәмев“ имзасы белән алмаштырылган.

Бу газеталарның җитәкчеләре бәйрәм даталарын шулай һәр вакыт „бергәләп“ билгелиләр. Узган елның 1 нче май, 7 нче ноябрь, 6 нчы сентябрь, 24 нче декабрь номерларын бу хәлдән бары тик „Стахановчы“ ның 4 бит, ә „Бондюг эшчесе“ нең 2 бит булып чыгуы гына коткарып калган, ләкин аларның да беренче битләренә бер үк материаллар урнаштырылган. Ә 21 нче декабрь номерлары 4 әр битле булып чыкканнар һәм бер-берсеннән бары тик исемнәре һәм редакторларының имзалары белән генә аерылалар.

Нигә шулай? Әллә район һәм завод җитәкчеләре үз газеталарын укымыйлармы? Укый торганнардыр, әлбәттә. Ә нигә соң шундый җиңел кәсепкә юл куела?

Ансын инде район җитәкчеләре үзләре әйтерләр.

КАЗАН МУЗЫКА УЧИЛИЩЕСЕНӘ ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ИСМЕ БИРЕЛДЕ

Казан Музыка училищесенә Татарстан АССР Верховный Советы исмен бирү турында Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының карары РСФСР Верховный Советы Президиумының 1940 нчы ел, 17 нче февраль указы белән расланды.

Казан Музыка училищесенең 35 еллык юбилее унае белән аңа ТАССР Верховный Советы исме бирелү турындагы хәбәрне училищенең укучылары һәм укытучылары зур күтәренкелек белән каршыладылар.

27 нче февральдә училищедә митинг булды. Училищенең директоры—Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклесе иптәш Әүхәдиев коллективны котлап, тагын да яхшырак эшләргә чакырды.

Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклесе Бормусов һәм композитор Виноградов, студент Сигель иптәшләрнең чыгышларын митинг алкышлар белән каршылады.

Бауман районындагы 39 нчы номерлы мәктәпнең 4 нче класс отличниклары. Алдагы рәттә—Нина Денисова. Арттагы рәттә—сулдан—Валя Григорьева, Регена Берман, Яша Кантон һәм Шура Полянин. М. Солтанов фотосы.

П. И. Чайковский юбилеенә хәзерлек

Шушы елның 7 нче маенда русның бөек композиторы П. И. Чайковскийның туына 100 ел тула. Бу гүзәл датаны илебезнең барлык почмакларында да зур тантана итеп билгеләп үтәчәкләр. Татарстанда да юбилейгә хәзерлек эшләре башланды. Татарстанның Сәнгат Эшләре Идарәсе янында 21 кеше составында хөкүмәт комиссиясе төзелде.

Комиссия күп кенә чаралар билгеләде. Чайковский юбилеен үткәрүдә Татарстанның барлык театрлары, культура, сәнгат учреждениеләре һәм музыка - сәнгат көчләре катнашалар.

Барлык предприятиеләрдә, учреждениеләрдә, уку йортларында һәм колхозларда Чайковский турында беседалар үткәреләчәк. Шәһәр докладчылары өчен музыка училищесенең педагоглары тарафыннан консультацияләр бирелә.

Татарстан Дәүләт филармониясе 15 нче апрельдән 15 нче майга кадәр Чайковский иҗадына багышлап музыка айлыгы үткәрә. Шәһәрдә 2 симфоник концерт бирергә уйланыла. Юбилей көннәре алдыннан районнарга 3 сәнгат бригадасы чыгачак.

Татар Дәүләт Опера театры юбилейгә Чайковскийның атаклы операсы „Евгений Онегин“ны куярга хәзерли. Апрель аенда театр артистлары көче белән Чайковский опералары өзекләреннән бер концерт биреләчәк.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры һәм Зур Драма театры коллективлары да юбилейгә хәзерлек алып баралар.

7 нче майда—юбилей тантанасы көнендә Кызыл Армия йортында Татарстанның сәнгат көчләре катнашы белән Чайковский кичәсе үткәрелә. Кичәдә җыр, оркестр, хор һәм балет номерларыннан концерт биреләчәк. Казан Кызыл Армия йортында бөек композиторга багышланган күргәзмә ачыла.

Казан Музыка училищесе һәм Татарстан радиокомитеты да юбилейгә зур хәзерлек алып баралар.

Халык җырлары җыентыгы һәм массовый җырлар

Татарстанның музыкаль-фольклор кабинеты республикабызның XX еллык юбилеенә күп төрле халык җырларын эченә алган музыкаль җыентык бастырып чыгара. Җыентыкка халык көйләреннән барлыгы 145 көй кертелде. Шулай ук балалар җырларыннан торган җыентык чыгарырга да уйланыла. Бу җыентыклардан тыш татар Совет композиторлары тарафыннан эшләнгән көйләрдән (халык көйләреннән) дә җыентык чыгарыла. Анда композиторлардан Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклеләре—Н. Җиһанов, А. Ключарев, композитор Мозаффаров һәм башкалар тарафыннан эшләнгән 50 гә якын көй кертелде. Җыентык инде басарга бирелде.

Кабинетның фәнни работникларыннан композитор Ключарев һәм шагыйрь М. Садрый иптәшләр май аенда Чкалов өлкәсенә экспедициягә баралар. Экспедиция анда, Октябрь революциясенә кадәр булган татар халык көйләрен җыячак. Шулай ук бер экспедиция Әтнә районына да җибәрелә.

Юбилей көннәрендә музыкаль-фольклор кабинеты материалларыннан радио буенча концертлар тапшырылачак.

Колхоз авылы үсә һәм ныгый

Бөек Октябрь революциясенә кадәр Кече Сунчалы иң артта калган авылларның берсе иде. Соңгы елларда бу авыл танымаслык булып үзгәрде. 3 елда „Сунча“ колхозы бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 13,5 центнер иген уңышы алып, Тельман районының гына түгел, бәлки республикабызның да алдынгы колхозлары сафына басты.

Элек Кече Сунчалыда укый-яза белүчеләр бармак белән генә санарлык булган. Ә хәзер „Сунча“ колхозы членнарының бөтенесе дә укый-яза белә. Алар арасыннан күп кенә кадрлар үсеп чыкты: 3 врач, 5 фельдшер, 47 укытучы, 2 летчик, 1 авиомеханик, 5 агроном, 5 бухгалтер, 5 лейтенант, 6 телеграфист, 2 радист, 2 механик, 5 инженер, 6 тракторчы, 4 комбайнчы һәм башка бик күп кадрлар хәзерләнде.

Колхозчылар колхозны ныгыту өчен өзлексез эш алып баралар, өстәмә доход чыганаклары эзлиләр. Мәсәлән, күп еллар буена ташландык хәлдә яткан 3 күлне 1938 нче елда чистарттылар һәм хәзер бу күлләрдә балык үрчетелә. Хәзерге көндә бу күлләрнең һәрберсендә 10 тонна чамасы балык бар дип исәпләнә. Үткән елны колхоз бу күлләрдән тотылган балыкны сатып 4 мең сумнан артык доход алды.

С. Фәхриев.

БАЛАЛАР ӨЧЕН ЯҢА ӘСӘРЛӘР

Балалар әдәбияты секциясенең 26 нчы февральдә үткәрелгән чираттагы җыелышы яңа әсәрләрне уку-тикшерүгә багышланды.

Беренче булып шагыйрь С. Хәким „Шагыйрьнең балачагы“ исемле әсәрен укыды. Халык шагыйре Г. Тукайның бай тормыш юлын иптәш С. Хәким күптәннән инде өйрәнеп килә. Шул өйрәнү һәм шул материал белән көчле дулкынлануы нәтиҗәсендә ул безгә „Пар ат“ исемле матур шигырьләрен бирә алды.

„Шагыйрьнең балачагы“ Тукайның балалык вактын чагылдырган истәлекләргә корылып эшләнгән һәм ул шагыйрьнең биографиясе өчен кирәкле булган, хәзергә кадәр матбугатта билгеле булмаган күп кенә нәрсәләрне үз эченә ала. Тыңлаучылар әсәргә югары бәя бирделәр һәм С. Хәкимне бу зур уңышы белән котладылар. Әсәрне тагын да киңәйтә төшәргә кирәк, дигән тәкъдимнәр дә булды. Аны бигрәк тә шул чор өчен характерлы социаль фактлар белән баетасы бар. Шулар яктылыгында Тукайның образын тагын да тулыландыра төшәргә мөмкин.

Шагыйрь Х. Туфан секция членнарын үзенең язачак әсәренең планы белән таныштырды һәм әсәренең язылган өлешен укыды. „Кем гаепле?“ исемле бу әсәр балаларны күзәтүсез, теләсә кая калдырып йөрүче ата-аналарны бик нык гаепли һәм каты тәнкыйть итә. Фикер алышуда сөйләүчеләр шагыйрьнең кайбер трактовкалары белән килешә алмадылар һәм аңа кыйммәтле генә күрсәтүләр ясап үттеләр. Иптәш Туфан шул күрсәтмәләрне кабул итеп, тиз көндә әсәрен эшләп бетерергә булды.

А. Алиш.

Гармон эшләү

Казан гармон фабрикасы узган елны 14.920 данә гармон, 11 аккордион, 74 баян, балалар өчен 8.369 гармон эшләп чыгарган иде. Быел фабриканың продукциясе шактый арта. 15.600 данә гармон, Ленинград гармон фабрикасы үрнәгендә 500 баян, балалар өчен 12.000 гармон эшләп чыгарырга билгеләнде. Фабрика балалар өчен 12 клавишлы уенчык пианино эшләүне үзләштерде. Быел 500 данә шундый пианино эшләнәчәк. Мондый уенчык пианино белән җиңел көйләрне бик матур итеп уйнарга мөмкин.

СУД

АКЧА ТУЗДЫРУЧЫ

Казан шәһәре, Бауман районының 3 нче участкы халык судында Горпромторгның элекке кассиршасы Т. И. Иванованың эше каралды.

Иванова 9 нчы номерлы магазинда эшләгән вакытында, узган елның 2 нче ноябрендә кассадан 6.555 сум акча алып чыгып киткән һәм акчаны туздырып бетергән булган. Халык суды Иванованы 5 елга иреккннән мәхрүм итүгә хөкем итте. Татарстан АССР Верховный Суды хөкем карарын раслады.

Көндәлек вакыйгалар

At караклары. „Волжанин“ артеленең йөкчесе Корнилов Зур Галактионов урамындагы 24 нче йорт ишеге алдында җигүле атын калдырып, үзе каядыр киткән булган. Шул чакта аның атын караклар урлап алып киткәннәр. Милиция тарафыннан чаралар күрелгәч, ат караклары Ершов кырында тотылганнар. Аларның берсе Ветеринария институты повары Гудков, икенчесе слесарь Автономов булып чыккан. Атны артельгә кайтарып биргәннәр.

ССР Союзы Җир Эшләре Халык Комиссариатының 1939 нчы ел, 17 нче декабрьдә чыгарган 746 нчы номерлы приказына туры китереп, „Сельхозхимснаб“ның 1939 нчы ел, 28 нче декабрьдә Өлкәара Горький конторасы буенча чыгарган 1 нче номерлы приказы нигезендә,—1940 нчы ел, 1 нче январьдан

„СЕЛЬХОЗХИМСНАБ“ НЫҢ ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ ОЕШТЫРЫЛДЫ

„Сельхозхимснаб“ ның Татарстан бүлеге „Сельхозхимснаб“ ның Өлкәара Горький конторасына карый һәм авыл хуҗалыгын минерал ашламалар, агулы химикатлар белән, шулай ук авыл хуҗалыгы үсемлекләренең корткычларына каршы көрәшү өчен кирәкле аппаратлар һәм ул аппаратларга кирәкле запас частьләр белән тәэмин итә.

„Сельхозхимснаб“ Татарстан бүлегенең адресы: Казан, Володарский урамы, 8. Телефон 21—39. Дәүләт Банкысы Татарстан Республика конторасында расчетлар счеты № 75041. 342—1

КАЗАН ХЕЗМӘТ САКЛАУ ИНСТИТУТЫНДА

җәмагать эшләре, техника, хокук һәм санитария инспекторлары һәм куркынычсызлык техникасы бүлеге мөдирләре өчен, шулай ук Наркомлегпром һәм Наркомместпром предприятиеләрендә хезмәт саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча эшләүче башка работниклар өчен, хезмәт саклау һәм куркынычсызлык мәсьәләләре буенча өстәмә рәвештә

кичке консультация оештырылды

Консультацияләр һәр айның 10 һәм 20 нче числоларында кич 6 сәгатьтән 8 гә кадәр үткәрелә. Казан, Комлев урамы, Хезмәт сарае, 2 нче кат, 29 нчы бүлмә. 356—1

Гражданнар игътибарына!

Бауман район страхование инспекциясе

гомерне һәм йорт җиһазларын коллектив һәм индивидуаль страхованиеләү эшләре үткәрә.

Гомерне һәм йорт җиһазларын страхованиеләү өчен—Чернышевский урамы, 9 адресы буенча килергә яисә 38—27 телефоны буенча страхование агентын чакыртырга.

328—3—2 Бауман районы страхинспекциясе.

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автотранспорт идарәсенең

ТОВАР-СКЛАД КОНТОРАСЫ

тимер юл станциясендә һәм пристаньдә клиентларның йөкләрен алу һәм озату буенча экспедицион, ә тимер юл станциясе һәм пристань складларыннан йөкләрне төяү яисә складларга бушату, шулай ук йөкләрне шәһәр складларында саклау буенча

клиентларына хезмәт күрсәтә

Югарыда күрсәтелгән эшләрнең йөкләрне күчерү белән бәйләнешле булганнарын контора үз транспорты белән үти.

Шартлары турында сөйләшү өчен түбәндәге адрес буенча килергә: Казан, Нәриман урамы, 40. Телефоннар: 43—82 һәм 3—96. 280—3—3

Главхимсбытның Горький өлкәара конторасының Казан базасы белдерә:

Наркомхимпромның приказы нигезендә

„СОЮЗЛАБОРРЕАКТИВ“ НЫҢ КАЗАН МАГАЗИНЫ ЭШЕН ТУКТАТТЫ

Магазинның барлык функцияләре, шулай ук хокуклары һәм үтәлергә тиешле бурычлары Главхимсбытның 1940 нчы ел, 1 нче январьдан яңа оештырылган Казан базасына күчерелде. Базаның адресы: Казан, Чернышевский урамы, 2 (элекке Союзлабореактив бинасы). Телефон 4—24. Дәүләт Банкысының Татарстан Республика Конторасында расчетлар счеты № 176006. 213—2—1

„Главкинопрокат“ ның Татарстан бүлеге

шушы көннәрдә Татарстан АССР киноэкраннарына, „Мосфильм“ кино-студиясендә эшләнгән

исемле тавышлы, художестволы яңа фильм-комедия бирә

Режиссер Т. Лукашевич. А. Барто һәм Рина Зеленая сценарийсы.

Баш рольләрдә артистлардан: Рина Зеленая, Ф. Раневская, П. Репнин һәм Р. Плят.

СТАХАНОВЧЫЛАР МӘКТӘБЕНЕҢ УҢЫШЛЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Безнең заводта 1939 нчы елга кадәр стахановчыларның тәҗрибәләрен уртаклашу бары тик производство киңәшмәләрендә генә алып барыла иде. Бу хәл стахановчылар санын арттыруга тулы булышлык итә алмады. Шуның өчен без үткән елны стахановчыларның кыска сроклы мәктәпләрен оештырдык. Бу мәктәпләргә иң беренче чиратта норманы үти алмаган, производство процессларын тулысынча үзләштереп җитмәгән яңа эшчеләрне тарттык.

Стахановчылар мәктәбе заводның барлык цехларында һәм бүлекләрендә оештырылды. Мәктәпне оештырган вакытта эшнең бер төрле булуын шарт итеп куйдык. Фрезеровщик, шлифовщик һәм строгальщиклар өчен аерым мәктәп оештырдык. Бу мәктәпләргә 3 тән алып 10 га кадәр кеше тартылды. Стахановчылар мәктәплренә җитәкчелек итү өчен һәрбер мәктәпкә цех начальниклары белән килешеп, стахановчылар, орденлылар беркетелде. Мәктәп белән җитәкчелек итү өчен билгеләнгән стахановчыларга инженер-техник работникларның булышлыгы оештырылды. Алар стахановчыларга конспект төзергә, эшне план белән алып барырга һәм аңлашылмаган мәсьәләләрне бергәләп чишүдә булышлык иттеләр.

Заводның иң яхшы стахановчысы иптәш Ганиев бу эшне беренче булып башлады. Һәм үткән елда 12 эшчене үзе җитәкчелек итә торган кыска сроклы мәктәпләр аркылы үткәрде. Мәктәпкә кадәр иптәш Мартынов норманы 85—90 процент үти иде. Хәзер ул заводның алдынгы эшчесе, норманы 300—315 процент һәм аннан да күбрәк үти. Элек норманы үти алмаган Абдуллин, Юсупов һәм башка күп кенә иптәшләр хәзер стахановча эшлиләр, яхшы сыйфатлы продукция җитештерәләр.

Начальнигы иптәш Орловцов булган цехта токарь булып эшләүче иптәш Коленин производство программасын системалы рәвештә үти алмый, күп брак эшли иде. Цех начальнигы иптәш Орловцов стахановчы иптәш Әхмәтҗановка, токарьлар группасында стахановчылар мәктәбен оештырып, аңа җитәкчелек итү эшен тапшырды. Иптәш Коленин мәктәпкә кереп укый башлагач көнлек норманы 182 процент итеп үти. Аның айлык хезмәт хакы 103 сумнан 438 сумга күтәрелде.

Иптәш Кузьмин җитәкчелек итә торган цехта элек план үтәлми, күп санда брак эшләнә иде. 1939 нчы елның октябрендә бу цехта 10 урында стахановчылар мәктәбе оештырылды һәм бу мәктәптә укучылар үзләренең укуларын барсы да уңышлы тәмамладылар. Ноябрь аенда яңадан 12 мәктәп оештырдык. Бу мәктәпләргә цехның алдынгы стахановчылары Ельсокова, Мельникова һәм Мортазин иптәшләр аеруча яхшы җитәкчелек иттеләр. Нәтиҗәдә цехта норма үти алмаучылар саны бик нык кимеде. Стахановчылар саны 35 процентттан 55 процентка артты.

1939 нчы елда безнең заводта стахановчылар мәктәбе 159 урында эшләде. Бу мәктәпләр белән стахановчылар җитәкчелек иттеләр. Мәктәпләрдә 700 дән артык кеше укып чыкты инде. Стахановчылар мәктәбен яхшы итеп оештыру аркасында заводта стахановчылар һәм ударниклар саны шактый артты. Хезмәт җитештерүчәнлеге үсте. Эш көчләренә экономия ясауга мөмкинлек бирде. Хезмәт җитештерүчәнлеге 1938 нче ел белән чагыштырганда 29,8 процент күтәрелде. Эшчеләрнең хезмәт хаклары 27,8 процент үсте. 1939 нчы елның башында бер эшченең уртача норма үтәве 126 процент булса, 1940 нчы елның 1 нче гыйнварена ул 148 процентка җитте.

Стахановчылар мәктәбенең яхшы эшләве күп станокларда эшләү һәм берничә профессияне үзләштерүгә бик нык ярдәм итте. Хәзер безнең заводта 130 кеше күп станокта эшләүгә күчте һәм 160 кеше берничә профессияне үзләштерде.

Иптәш Кузьмин җитәкчелек итә торган цехта эшләүче, Шәһәр Советы депутаты иптәш Вахонин 3 кеше эшли торган эшне бер үзе башкара һәм нормасын 185 процент итеп үти. Орденлы бригадир иптәш Тимофеевны заводта белмәгән кеше юк. Ул үзенең яхшы эш тәҗрибәләрен артта калучыларга өйрәтә. Әле күптән түгел генә ул 35 кешене катлаулы станок һәм машиналарда эшләргә өйрәтеп чыгарды.

Стахановчылар мәктәбе тагын да яхшырак нәтиҗәләр бирсен өчен 1940 нчы елда бу эшне тагын да яхшыртабыз. Кузьмин, Орловцов, Оборин һәм Котельников иптәшләр җитәкчелек итә торган цехларда январь аенда 47 мәктәп үзенең эшен уңышлы тәмамлады. Бу мәктәпләрдә укып чыккан 212 кешенең күпчелеге хәзер стахановча эшлиләр. Стахановчы иптәш Гайнеттинов җитәкчелек иткән мәктәптә укып чыккан 9 кешенең хәзер 7 се норманы 128—192 процент итеп үтиләр. Яхшы сыйфатлы продукция җитештерәләр.

Уңышлы яклар булу белән бергә, әле бу өлкәдә җитешсезлекләр дә юк түгел. Заводның кайбер цех начальниклары стахановчылар мәктәпләренең бу гүзәл эш тәҗрибәләрен күрергә теләмиләр. Мәктәпләрнең тагын да яхшырак эшләүләре өчен тиешле булышлык итмиләр. Завод директоры да бу эшкә җитәрлек әһәмият бирми. Заводның партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары җитәкчеләре бу эшкә якыннан торып булышлык итәргә тиешләр.

Әхәт Шамиев.

Серго исемендәге заводның стахановчылар методы инструкторы, Шәһәр Советы депутаты.

Җаваплы редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.

Зам. ответ. редактора И. УЗБЕКОВ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн РСФСР ның атказанган артисты орденлы

М. ЗОЛЛО

гастрольләре

Яңартылган репертуарда көлке номер:

„МӘЕТ КҮМҮ“

хайваннар һәм кошлар башкаруында һәм башка номерлар.

1 нче мартта көндез 12 сәгатьтә зур программа буенча

КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ

Билетлар түбәнәйтелгән бәядән.

ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ хәзерләнә.

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 29 нчы февральдә **ЛЕНИН** Талон 112.

1 нче мартта көндез 12 сәгатьтә **ЛЕНИН** (Талон 23),

кич **МАСКАРАД** (талон 113).

Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында

Бүген, 29 нчы февральдә һәм 3 нче мартта

ИРЕК

Талоннар: бүген 80, 3 нче мартта 81.

Уен 7 сәгат 30 минутта башлана.

Билетлар ТДАТ кассасында сатыла.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Физкультура һәм Спорт эшләре комитеты Автомотоклубы янындагы

АВТОМӘКТӘП

III нче класс шоферлардан II нче һәм I нче класс шоферлар хәзерләү буенча

шушы ел, 5 нче марттан

КУРСЛАР АЧА

Шулай ук, III нче класс любитель шоферлар, профессионал шоферлар һәм газогенераторчылар хәзерләү группаларына

УКУЧЫЛАР АЛА

Укыту расходлары өчен түләү командировка биргән оешмалардан яисә укучының үзеннән алына. Башка шәһәрләрдән һәм урыннардан килүчеләргә тулай торакта урын бирелә. Казан, Куйбышев урамы, 1, Автомотоклубның укыту бүлеге. 386—2—1

Киров районындагы КУЛЬТУРА САРАЕНДА

ТДАТ спектакльләре

Бүген, 29 нчы февральдә

БИШБҮЛӘК

Талоннар 60 һәм 61.

Спектакль кич 8 дә башлана.

ГОРЖИЛСНАБ

Чернышевский урамындагы 2 нче йорттан Астрономия урамындагы 8 нче йортка

КҮЧТЕ.

268—2—2

3 фазалы, беренче басымы 6.000 вольт, икенче басымы 220-380 вольт һәм 100 киловатт куәтле яңа

ТРАНСФОРМАТОРНЫ

икенче басымы 127-220 вольтлы шундый ук трансформаторга

АЛМАШАБЫЗ

Казан, Холодильник. Телефон 22—76. 154—2—3

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ЧЫҢГЫЗ ХАН НӘСЕЛЕ
„ПИОНЕР“ 10-40, 1, 2, 4-30, 7 һәм 9-30.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	БАЛТЫЙКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	БЕЗ КРОНШТАДТТАН